Согласовано
Заместитель директора по ВР
М.Р.Набиева
от «31» августа 2023г.

Утверждаю
Директор
МБОУ «Адымнар-Нижнекамск» НМР РТ
А.К.Галиахметов
Приказ № 333
от «31» августа 2023г.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 582CA7008FB0A79C414293C8C3420099
Владелец: Галиахметов Артур Каримович
Действителен с 02.10.2023 до 02.01.2025

Дополнительная общеобразовательная программа
художественно-эстетической направленности
«Күңелле татар теле»
*Срок реализации - 1 год*
*Для учащихся 1 классов*

Руководитель:
Губайдуллина Э.А.
учитель начальных классов

2023 г.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Эчтәлек**


| | | |
|---|---|---|
| 1. | Аңлатма язуы | 3 |
| 2. | Программаның эчтәлеге | 7 |
| 3. | Укыту-тематик план | 10 |
| 4. | Кулланылган әдәбият | 12 |


## Аңлатма язуы

“Яшь талантларның  беренче авазларын сез мәктәп залларыннан ишетерсез. Дөньяга сирәк килә торган Тукайларның яшьлеге сезнең кулда” (С.Хәким)

“Күңелле татар теле” программасы – комплекслы, интеграль программа; “Риторика”, “Театр” курсларын үз эченә ала.

Программаның максатлары гомуми белем бирү максатларына туры килә. Башлангыч мәктәпнең перспектив максатларына яраклаштырылган.

Риторика укучыларны дөрес,оста,нәтиҗәле итеп сөйләргә, язарга һәм аралашырга өйрәтә, балада предметара югарылыктагыуниверсаль эшчәнлек нигезләрен сала.Бу предмет информацияле җәмгыять, инновациялеэкономика,толерантлык,сөйләшү әдәбе һәм күпмилләтле җәмгыять мәсьәләләрен хәл итәргә ярдәм итә.

Хәзерге заман мәктәбе һәм өстәмә белем бирү системасыныңюнәлешенең берсе - барлык укыту-тәрбия эшенең тәрбия функциясен көчәйтү. Гасырлар буена театр белем бирү һәм культура традицияләре белән тыгыз бәйләнештә торган.

“Күңелле татар теле” программасы дәресләр рамкасында гына чикләнми,балаларның мөстәкыйль иҗатын үстерү максатын тормышка ашыра. Программаны тормышка ашыруның төп принцибы – тәрбия-белем эшчәнлеген дифференцияләштерү. Коллектив эш формаларына өстенлек бирелгән хәлдә ,программа һәр тәрбияләнүченең индивидуаль үзенчәлекләрен, мөмкинчелекләрен һәм сәләтен исәпкә ала.

Сөйләмне ишетү сәләте (сөйләмне аңлау, авазларны бер-берсеннән аеру) түбән балалар ишеткән авазны бик тиз “тотып алып” аны билге(хәреф)белән туры китерә алмый.Сөйләм үсешендәге кимчелекләрне төзәтү максатында, программа эчтәлегенә тел төзәткечләр, тел шомарткычлар өйрәнү, артикуляция күнегүләрен үткәрү кертелде.

**Программаның актуальлеге**

Безнең җәмгыять өчен балалар һәм яшүсмерләр театры бик кирәк.Балалар балачак рәхәтлеген тулысынча тоймыйлар,торган саен азрак хәрәкәтләнәләр, үз гәүдәләре белән идарә итә алмыйлар,үз тавышларына ия була алмыйлар.Театр балаларга ачылырга,үзенең балалыгын уйнарга,тормышта,иптәшләре,кешеләр арасында үз урынын табарга ярдәм итә.  Кайчандыр бөек рус шагыйре А.С.Пушкин театрны “тылсымлы дөнья”дип атаган иде. Спектакльдә тамашачы гына түгел,катнашучы булу балага зур шатлык бирә.

Биремнәрне кабатлау, сәхнәдә чыгыш ясау нәтиҗәсендә балалар “үз-үзенә бикләнгәнлек”не җиңәләр, кыюлык, ышаныч яулыйлар. Аларда бердәмлек, җаваплылык, мәрхәмәтлелек хисләре формалаша.

Шөгыльнең төп элементы  - уен. Уен аша балада үз-үзен,иптәшләрен,әйләнә-тирә дөньяны танып-белү теләге уяна. Бала театр аша бөтендөнья әдәби сәнгате белән кызыксына, һәр эшкә иҗади якын килергә өйрәнә.

Театр – тылсымлы дөнья! Һәр буын кешеләренең күңелләрендә театр буенча күңелле истәлекләр саклана. Мәктәп яшендәге  балаларда ул  соклану,түземлелек, мавыгу сыйфатлары тәрбияли.

Баланы эмоциональ баетуга,оялчанлыкны бетерүгә,хисләнә,хыяллана белүгә иң кыска юл – уен, фантазия, иҗат аша. Моның барысына да театр аша ирешеп була.

Театр уены уңай кичерешләргә генә юнәлдерелми. Баланы уңышсызлыклардан курыкмаска өйрәтергә кирәк. Бу аның характерын ныгыта, җиңелүен кичерергә өйрәтә, үзара килешү юлларын эзләргә этәрә.

Курчак театры балаларга аеруча якын, аларга зур тәрбияви йогынты ясый. Шуның өчен репертуар сайлауга зур әһәмият бирү кирәк. Спектакльдә чын дуслык,намуслылык,кыюлык,мәрхәмәтлелек күрсәтерсә,бик яхшы була. Курчак театрында һәр баланы катнаштырырга мөмкин.Курчак театры өчен пьесаны балаларның үзенчәлекләрен исәпкә алу, алар белән бергәләп язу отышлы.

Курчак – актёр кулы һәм фантазиясе ярдәмендә җансыз материягә “җан кертү”. “Җанланган” геройлар яңа образлар тудыралар:балада уйлау процессы эшкә җигелә. Курчак аша баланың сөйләм теле үсә.

**Программаның яңалыгы**

1.Укыту-тәрбия эшчәнлеге төрле эш юнәлешләре аша тормышка ашырыла:
- тамашачы культурасы нигезләре тәрбияләү;
- башкаручы эшчәнлеге күнекмәләре тәрбияләү;
- театр турында белемнәр туплау;

Бу эш юнәлешләре үзара үреләләр, бер-берсен тулыландыралар, нәтиҗәдә, тәрбияләнүченең әхлак сыйфатларын тәрбиялиләр.

2. Һөнәри психологлар һәм драматурглар балалар неврозын дәвалау ысулын уйлап тапканнар. Берничә ел инде алар "тәрбиягә авыр бирелүче" балалар һәм аларның әти-әниләре белән эш барышында курчак терапиясен кулланалар:балаларны курчак театры ярдәмендә дәвалыйлар.

Театр эшчәнлеге балада әдәбиятка, театрга карата кызыксыну уята. Балаларның тормышы кызыклырак,эчтәлеклерәк була бара. Иҗат шатлыгын тою аларны куандыра.

Дөрес юнәлеш биргәндә, балада артист, режиссёр, театр рәссамы, дирижёр хезмәте турында күзаллау формалаша. Аның танып-белү эшчәнлеге ныгый. Бала берникадәр вакытка герой булып тора, үз-үзенә бәя бирә, үз гомерендә беренче кул чабуларны ишетә.

Театр – коллектив хезмәт . Спектакль – коллективның иҗади тырышлыгы нәтиҗәсе.Театр дәресләре балаларда бердәмлек,чын дуслыкның кадерен белү, үз-үзеңә һәм башкаларга карата таләпчәнлек тәрбияли.

3. Класста сөйләмне ишетү сәләте түбән булган укучы укый. Аны укырга-язарга өйрәтү бик авыр педагогик проблема булып тора. Программага баланың сөйләм үсешендәге кимчелекләрен ачыклап, укыту-тәрбия чаралары ярдәмендә аларны төзәтү һәм булдырмый калу эше кертелде:

1) Авазларны әйтүдәге кимчелекләрне коррекцияләү.
-артикуляр моториканы үстерү;
-сулыш алуны ныгыту;
-авазларны кую, автоматлаштыру һәм дифференцияләштерү;
2) Укучыларның фонематик ишетү сәләтен, анализ, синтез, кабул итү сәләтләрен үстерү.
3) Актив һәм пассив сүзлек запасын баету.
4) Сөйләмдә дөрес лексик-грамматик категорияләр формалаштыру.
5) Бәйләнешле сөйләм үстерү

**Программаның максаты** – балалар риторика курсы һәм театр педагогикасына нигезләнеп, толерантлы, эчке культурага ия булган иҗади шәхес тәрбияләү.

**Белем бирү максатлары:**
• Театр сәнгате аша гомум сәнгать дөньясына якынайту.
•Театр дисциплинасының элементар нигезләрен белү.
•Үзеңнең һәм иптәшләреңнең тәртибенә тактлы итеп бәя бирә белү.
• Татар халкының тарихы,йолалары белән танышу.

**Үсеш максатлары:**
•Дәрестә алган белемнәрне тирәнәйтү һәм киңәйтү,аларны тормышта гамәли куллана белү күнекмәләре бирү.
•Рольне өйрәнгәндә эшкә иҗади якын килү күнекмәсен үстерү.
• Сөйләм күнекмәләрен үстерү.
•Күз алдына китерә, хыяллана белү сәләтен, хәтерне, игътибарлыкны үстерү.
• Балаларның спектакль карау тәҗрибәсен киңәйтү.
•Сәламәтлекне ныгыту: гәүдә-сын төзелешенең зифа булуына омтылу.

**Тәрбия максатлары:**
•Үзен иркен тотучы, аралашучан, иҗади актив Кеше тәрбияләү.
•Әдәби һәм драма әсәрләрен аңлап, сәнгатьле уку культурасы тәрбияләү.
•Бер-береңә теләктәшлек итү теләген тәрбияләү.
• Әдәби зәвык тәрбияләү.
•Эстетик зәвык тәрбияләү.
-зәвык белән киенү;
-сәхнәдә үз-үзеңне дөрес тоту;
-хәрәкәтләрнең музыкага ярашлы,сыгылмалы булуы;
•Коллективта үзен дөрес тоту күнекмәләре тәрбияләү.

• Репетиция вакытында үзара әдәпле аралашукүнекмәләре тәрбияләү.
•Балаларда лидер сыйфатлары тәрбияләү.
•Кешеләргә шатлык китерү теләге тәрбияләү.
• Туган авыл,мәктәп белән горурлану хисе тәрбияләү.
•Юмор хисе тәрбияләү.
•Мәрхәмәтлелек,кайгыртучанлык сыйфатлары тәрбияләү.

**Бурычлары:**

-укучының шәхси сәләтен ачу,табигый сәләтен үстерү;
-уен аша баланың эчке дөньясын һәм гәүдә сыгылмалылыгын үстерү;
-образлы фикерләү сәләтен үстерү;
-уйлау һәм танып-белү эшчәнлеген үстерү;
-авазларны дөрес итеп әйтергә күнектерү;
-ишетә һәм тыңлый белү;
-ритмны ,пространствоны һәм вакытны күзаллау сәләтенә ия булу;
-баланың ритмны тоеп,хәрәкәтләрен яраклаштыра белү сәләтен үстерү;
-тере җан ияләре һәм предметларның образын үз гәүдәңнең сыгылмалылык мөмкинчелекләре аша күрсәтү;
-мимика һәм ишарә аша образлар тудыру;
-музыка аша көйне тоя белүне үстерү;
-артикуляр гимнастика аша сөйләм аппаратын үстерү;
-дөрес сулыш алу,сулыш чыгаруның 3 төрен куллана белү;
-дикцияне үстерү;
-сузык һәм тартык авазларны дөрес әйтү;
-тавышның көчен һәм киңлеген үстерү;
-төп хисләрне белдерүче интонацияләрне кулланырга өйрәтү;
-курчак театры нигезләре белән таныштыру;
-театр костюмнарына, курчакларга сакчыл караш тәрбияләү;
-үзара дуслык һәм түземлелек сыйфатлары тәрбияләү;
-балаларны сәхнәдә эшләү алдыннан курыкмаска өйрәтү;
-репетиция вакытында үзара әдәпле аралашукүнекмәләре тәрбияләү.

**Программаны тормышка ашыру нигезендә түбәндәге принциплар ята:**

- уку материалын тематик планлаштыру;
- җиңелдән авырга бару;
- һәр баланың  актив катнашуы;
- эш төрләрен чиратлаштыру;

Балаларның театр эшчәнлеге **үстерешле укыту принципларына** нигезләнә.
Түбәндәге **методлар** кулланыла:

- киеренкелек тудыручы сәбәпләрне бетерү;
- уен һәм өйрәнүнең мәҗбүри булмавы;
- эчке,шәхси мотивларның өстенлек итүе;
- “мин барын да булдырам”теләген уяту;

Дәресләрдә **уңайлы халәт тудыру** максатында педагог:

- балалар белән үзара педагогик хезмәттәшлеккә нигезләнә;
- балаларга җылы,түземле караشта була;
- уен  элементларын мөмкин кадәр күбрәк куллана;

**Программаны тормышка ашыруның төп методлары:**

- театральләштерү методы;
- эмоциональ драматургия методы;
- «гадидән катлаулыга» эш методы;
- уен.

Программа өстәмә белем бирү педагогы эшчәнлегенең өч төп сыйфатына нигезләнә:
- педагогик эшчәнлекне гуманлаштыру ;

- индивидуаль һәм  и дифференциаль якын килү ;
- демократияләштерү;
**Өйрәтү методлары :** группада эшләү, индивидуаль, уздырышлы укыту, дифференцияле, иҗади, теоретик, практик күрсәтмәле, ИКТ.
**Яңа технологияләр куллану**: проблемалы метод (педагог проблеманы чишәргә ярдәм итә), эзләнү методы (балалар проблеманы үзләре чишәләр,педагог нәтиҗә ясый), эвристика методы(педагог аңлата+балаларның иҗади эзләнүләре), тулы авырлык бирү методы(тренинглар чылбыры)
**Өйрәтү формалары**: әңгәмә, хикәя, проблемалы хәлне ачыклау, чыгышлар язылган видеокассета буенча фикер алышу,театрга,музейга бару, тематик экскурсияләр,   тренинг, группалы күнегүләр, текст белән эш, репетиция, бәхәс, сәхнәдә уйнап күрсәтү, слайдлар карау, музыка тыңлау, театр педагогикасыннан уеннар, сюжетлы-рольле уеннар, конкурс һәм викториналар, дәрес-сәяхәт, зачёт-дәрес.
**Программаны тормышка ашыру өчен  шартлар.**
**Җиһазлау.** Театр костюмнары, курчаклар, курчак театры өчен пәрдә, декорация кирәк. Спектакль өчен сәхнә мәйданчыгы, репетиция залы, музыкаль бизәлеш өчен аппаратура, грим, париклар таләп ителә.
**Күрсәтмә материал.**
**Иллюстрацияләр**: ”театр тарихы”, ”сәхнә костюмы”, ”театр гримы” һ.б.
**Таратма материал**: ”Тавыш өстендә практик эш”, “Күнегүләр” карточкалары.
**Тикшерү материалы**: биремле карточкалар, иҗади биремнәр, тестлар, кроссворд, викториналар.
**Көтелгән нәтиҗәләр**
**1 нче уку елы ахырына укучылар :**
• Сөйләмнең кеше тормышындагы әһәмиятенаңлыйлар.
• Аралашуның (исәнләшү,гафу үтенү һ.б.) кайбер кагыйдәләрен  куллана беләләр.
• Дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә кайбер әдәплелек кагыйдәләрен куллана беләләр.
• Әңгәмә алып баралар.
• Текстны аера беләләр.
• Текстны мәгънәви кисәкләргә бүлә беләләр.
• Текстка уңышлы исем сайлыйлар.
• Терәк сүзләр, рәсемнәр  кулланып,бирелгән сюжет буенча хикәя, шигырь язалар.
• Шигырь текстына гади рифмалар таба беләләр.
• Санамышлар  башкара, уйлап таба беләләр.
• Сөйләмнең  әдәплелек дәрәҗәсен билгели һәм бәяли  беләләр.
• Төп терминнар:театр, сәхнә, этюд һ.б.куллана беләләр.
• Психофизик тренингка 5-10 күнегү беләләр.
• Проблемалы авазларга 5-7 яңа тизәйткеч беләләр.
• 5-10 сөйләм күнегүен беләләр.
• Коллективта эшли беләләр.
• Ачык,аңлаешлы,матур сөйли беләләр.
• Тылсымлы” сүзләрне урынлы куллана беләләр.
• Тавыш төсмере һәм тавыш көченнән,интонациядән урынлы файдаланалар.
• Балаларның спектакль карау тәҗрибәсен киңәя.
• Сәхнәдә эшләү алдыннан курыкмаска өйрәнәләр.
• Мускул киеренкелеген бетерә беләләр.
• Курчаклар белән эшли беләләр.

## Программаның эчтәлеге

1. **Кереш дәрес**

Башлангыч диагностика

2. **Аралашу**

**Тема 1. Хезмәт, тормыш-көнкүреш темасына җырлы-биюле уеннар**: “Тау башында карлыган”, “Уңышлар җыябыз”.

**Тема 2. Дуслык темасына җырлы-биюле уеннар**: ”Кәрия-Зәкәрия”, “Дус булыйк”. Үзеңнең хәрәкәтләреңне җыр эчтәлегенә һәм иптәшләреңнең хәрәкәтләренә туры китерү.
**Тема 3. Оялчанлыкны бетерү.**
”Әйдәгез,танышабыз”- тренинг.
Йөгерә үрдәк,йөгерә каз”, “Наза” җырлы-биюле уеннары.
**Тема 4. Кем белән сөйләшәсең? Син сөйлисең-мин тыңлыйм**.
Әңгәмәдәшне тыңларга өйрәнәбез.
“Иптәшеңә ярдәм ит, кычкырма, җайлап аңлат” кагыйдәсен истә калдыру.
Практик күнегүләр:
1.Эстафета-чылбыр.
2.Бер үк эшне төрлечә.
3.Телепатлар.

3. **Сөйләм культурасы**

**Тема 1.** Әдәпле кеше ничек сөйләшергә тиеш?
**Тема 2. Тылсымлы сүзләр.**
“Тылсымлы”сүзләрне чын күңелдән, урынлы куллана белергә өйрәнү.
**Тема 3. Әдәпле кеше нинди була?**
Әдәпле,ягымлы сүзләрне урынлы куллану.
**Тема 4. Телефоннан ничек сөйләшергә?**
Телефоннан сөйләшү-сөйләмнең бер төре.Төрле ситуацияләрдә сөйләм төзи белү.

4. **Сөйләм техникасы**

**Тема 1. Авазларны дөрес әйтүгә күнегүләр.**
Сүздәге һәр авазны ачык әйтеп,кушымчаларны “йотмыйча” әйтү. Логик басымны,паузаны дөрес билгеләү. Үзеңне персонаж урынына куеп карау.Аның өчен ничек укырга һәм ни өчен шулай укырга?
Практик күнегүләр:
1.Шәм белән уеннар.
2.Сабын күбекләре.
3.Өйрәтелгән этләр.
Дөрес сулыш алуга күнегүләр.
Рольләрне өйрәнгәндә сулыш алу кагыйдәләрен үтәү.
**Тема 2. Мимика һәм ишарә нәрсә турында сөйли?**
а)Ишарәне дөрес куллана белү.
“Самолётлар һәм күбәләкләр”уены
б)Мускулларның төп группаларын чиратлаштырып киеренкеләндерү һәм йомшарту.
“Көзге яфраклар”уены
в)Кроссворд чишү. Җавапны мимика,ишарә,хәрәкәт аша күрсәтү.
г)Пантомима-сәнгатьнең бер төре.
Пантомима күрсәтүгә күнегүләр.
д)”Ут һәм су”уены
**Тема 3.Тавыш төсмере – тембр. Тавыш көче.**
Магнитофон язмасыннан “Гөлчәчәк”әкиятен һ.б.язмаларны тыңлау.

5. **Сөйләм эшчәнлеге**

**Тема 1. Логика, күз алдына китерү, хыяллана белү, игътибарлылык, күзәтүчәнлек, хәтерне үстерүгә уеннар.**
Практик күнегүләр:
1.Син нәрсә ишетәсең?
2.Кем ничек киенә?
3.Игътибарлы курчаклар.
4.Күләгә.
5.Нәни пешекчеләр.
6. 5 сизү органына күнегүләр.
7.Игътибарлы җәнлекләр.

**Тема 2. Рәсем буенча хайванны сурәтләү. Картина буенча хикәя төзү.**
**Тема 3.** Әкиятләр илендә.
Әкиятне герой исеменнән сөйләтү. Минем әкиятем.
**Тема 4. Тизәйткечләр, санамышлар.**
Сөйләм төрле тизлектә кулланыла.Тизәйткечләрне дөрес әйтергә өйрәнү (тизлек, ритм, интонация).
Санамышлар өйрәнү.
**Тема 5.** Без шигырь яратабыз. "Рифма"төшенчәсе.
Шигырьләр уку, хайваннарны хәрәкәтләр белән күрсәтү.
Шигырь  язу күнегүләре.
**Тема 6. Кем күбрәк укый?**
"Әдәби фикер", "Бу әйберләр кайсы әкияттән югалган?","Нәрсә артык?"уеннары.

6. **Театр культурасы нигезләре**

**Тема 1.** Театрда үз-үзеңне дөрес тоту.
**Тема 2.** Сәхнә сәнгате белән кызыксыну уяту.
Артистлар чыгышында курчак театры спектаклен карау.

7. **Сәхнәләштерү**

**Тема 1**. Барыбыз бергәләп әкиятне "җанландырабыз"
Партнёр белән аралашу.
Практик күнегүләр:
1.Көзге.
2.Фотограф.
3.Телефон.
4.Этюдлар.
5.Эзгә-эз.
**Тема 2.** "Ике кыз"курчак театрына әзерлек.Репетиция.
**Тема 3.** "Ике кыз"курчак театрына әзерлек . Репетиция.Курчак театры өчен костюмнар,декорация әзерләү.
**Тема 4.** "Ике кыз"курчак театрын сәхнәләштерү.
**Тема 5.** "Серле урман" курчак театрына әзерлек. Репетиция.
**Тема 6.** "Серле урман" курчак театрына әзерлек. Курчак театры өчен костюмнар, декорация әзерләү.Репетиция.
**Тема 7**. "Серле урман" курчак театрын сәхнәләштерү.
**Тема 8**.  "Аулак өй" әзерлек. Рольләр бүлешү, музыка билгеләү, костюмнар, декорация әзерләү. Репетиция.
**Тема 9.** "Аулак өй" сәхнәләштерү
**Тема 10.** "Өч кыз" татар халык әкиятен сәхнәләштерүгә хәзерлек. Рольләр бүлешү ,костюмнар, декорация әзерләү. Репетиция
**Тема 11**. "Өч кыз" татар халык әкиятен сәхнәләштерү.

8. **Иҗади проект**

**Тема1.** "Чисталык патшалыгында" әкиятен иҗат итү.
**Тема2.** "Чисталык патшалыгында" әкиятен сәхнәләштерүгә хәзерлек. Театр өчен костюмнар, декорация әзерләү. Репетиция.
**Тема3.** "Чисталык патшалыгында" әкиятен сәхнәләштерү. Авыл клубы сәхнәсендә, балалар бакчасында, төп мәктәп укучылары алдында, инвадид өлкәннәрнең өйләренә барып чыгышлар ясау.

Йомгаклау. Диагностика.

**Укыту-тематик план**

| № п/п | Төп темалар | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес | 1 |
| 2 | Аралашу | 7 |
| 3 | Сөйләм культурасы | 4 |

| | | |
|---|---|---|
| 4 | Сөйләм техникасы | 5 |
| 5 | Сөйләм эшчәнлеге | 9 |
| 6 | Театр культурасы нигезләре | 3 |
| 7 | Сәхнәләштерү | 28 |
| 8 | Иҗади проект | 9 |
| | **Барысы:** | **66** |

## Календарь-тематик план

| № | Дәресләр темасы | Сәгать саны | План | Факт |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **1. Кереш дәрес**<br>Башлангыч диагностика | 1 | 06.09 | |
| | **2. Аралашу - 7 сәгать** | | | |
| 2-3 | Хезмәт, тормыш-көнкүреш темасына җырлы-биюле уеннар. | 2 | 08.09<br>13.09 | |
| 4-5 | Дуслык темасына җырлы-биюле уеннар.Үзеңнең хәрәкәтләреңне җыр эчтәлегенә һәм иптәшләреңнең хәрәкәтләренә туры китерү. | 2 | 15.09<br>20.09 | |
| 6-7 | Оялчанлыкны бетерү өстендә эш | 2 | 22.09<br>27.09 | |
| 8 | Кем белән сөйләшәсең? Син сөйлисең-мин тыңлыйм.<br>Курай - музыка уен коралы белән танышу | 1 | 29.09 | |
| | **3. Сөйләм культурасы – 4 сәгать** | | | |
| 9 | Әдәпле кеше ничек сөйләшергә тиеш? | 1 | 04.10 | |
| 10 | Тылсымлы сүзләр. | 1 | 06.10 | |
| 11 | Әдәпле кеше нинди була? | 1 | 11.10 | |
| 12 | Телефоннан ничек сөйләшергә? | 1 | 13.10 | |
| | **4. Сөйләм техникасы – 5 сәгать** | | | |
| 13 | Авазларны дөрес әйтүгә күнегүләр.<br>Дөрес сулыш алуга күнегүләр | 1 | 18.10 | |
| 14-15 | Мимика һәм ишарә нәрсә турында сөйли? | 2 | 20.10<br>25.10 | |
| 16-17 | Тавыш төсмере – тембр. Тавыш көче. | 2 | 27.10<br>08.11 | |
| | **5. Сөйләм эшчәнлеге – 9 сәгать** | | | |
| 18-19 | Логика, күз алдына китерү, хыяллана белү, игътибарлылык, күзәтүчәнлек, хәтерне үстерүгә уеннар. | 2 | 10.11<br>15.11 | |
| 20-21 | Рәсем буенча хайванны сурәтләү. Картина буенча хикәя төзү. | 2 | 17.11<br>22.11 | |
| 22-23 | Әкиятләр илендә. | 2 | 24.11<br>29.11 | |
| 24 | Тизәйткечләр, санамышлар. | 1 | 01.12 | |
| 25 | Без шигырь яратабыз. “Рифма”төшенчәсе. | 1 | 06.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26 | Кем күбрәк укый? | 1 | 08.12 | |
| **6. Театр культурасы нигезләре – 3 сәгать** | | | | |
| 27 | Театрда үз-үзеңне дөрес тоту. | 1 | 13.12 | |
| 28-29 | Сәхнә сәнгате белән кызыксыну уяту. Артистлар чыгышында курчак театры спектаклен карау. | 2 | 15.12<br>20.12 | |
| **7. Сәхнәләштерү – 28 сәгать** | | | | |
| 30 | Барыбыз бергәләп әкиятне “җанландырабыз” | 1 | 22.12 | |
| 31-32 | “Ике кыз”курчак театрына әзерлек. Рольләр бүлешү. Репетиция. | 2 | 27.12<br>10.01 | |
| 33-35 | “Ике кыз”курчак театрына әзерлек Репетиция. Курчак театры өчен костюмнар, декорация әзерләү. | 3 | 12.01<br>17.01<br>19.01 | |
| 36-37 | “Ике кыз” курчак театрын сәхнәләштерү. | 2 | 24.01<br>26.01 | |
| 38-39 | “Серле урман” курчак театрына әзерлек. Рольләр бүлешү. Репетиция. | 2 | 31.01<br>02.02 | |
| 40-42 | “Серле урман” курчак театрына әзерлек. Курчак театры өчен костюмнар, декорация әзерләү. Репетиция. | 3 | 07.02<br>09.02<br>14.02 | |
| 43-45 | “Серле урман” курчак театрын сәхнәләштерү. | 3 | 16.02<br>28.02<br>01.03 | |
| 46-48 | “Аулак өй”әзерлек. Рольләр бүлешү, музыка билгеләү , костюмнар, декорация әзерләү. Репетиция. | 3 | 06.03<br>13.03<br>15.03 | |
| 49-51 | “Аулак өй” сәхнәләштерү | 3 | 20.03<br>22.03<br>03.04 | |
| 52-54 | “Өч кыз” татар халык әкиятен сәхнәләштерүгә хәзерлек. Рольләр бүлешү, костюмнар, декорация әзерләү. Репетиция | 3 | 05.04<br>10.04<br>12.04 | |
| 55-57 | “Өч кыз” татар халык әкиятен сәхнәләштерү | 3 | 17.04<br>19.04<br>24.04 | |
| **Иҗади проект – 9 сәгать** | | | | |
| 58-60 | “Чисталык патшалыгында” әкиятен иҗат итү. | 3 | 26.04<br>30.04<br>03.05 | |
| 61-63 | “Чисталык патшалыгында” әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек. Рольләр бүлешү. Театр өчен костюмнар, декорация әзерләү. Репетиция. | 3 | 08.05<br>10.05<br>15.05 | |
| 64-65 | “Чисталык патшалыгында” әкиятен сәхнәләштерү. | 2 | 17.05<br>22.05 | |
| 66 | Йомгаклау. Диагностика. | 1 | 25.05 | |

## Кулланылган әдәбият


1. Вербицкая Л.А. «Давайте говорить правильно!» М., 2010 г.

2. Генералова И.А.   Программа «ТЕАТР»
3. Голуб И.Б., Розенталь Д.Э. Секреты хорошей речи. М., 2007 г.
4. Граудина Л.К., Русская риторика. Хрестоматия, М., 2006 г.
5. Ершова А.П. «Уроки театра в школе.2010г.
6. Королев М.М. Искусство театра кукол. Основы теории. Л., Искусство, 2007 г.
7. Кристи Г.В. Основы актерского мастерства. Советская Россия, 2010 г.
8. Кузнецова Т. Театр кукол: Программа обучения детей.2006г.
9. Ладыженская Т.А. "Речевые уроки", Москва, Просвещение, 2005 г
10. Медведева И. “Куклотерапия, или что такое  драматическая психоэлевация”2005г.
11. Михалевич А.Е.«О красноречии в шутку и всерьез», М., 2009 г.
12. Образцов С.В. Всю жизнь я играю в куклы. М., 2005 г.
13. Обухова Л.А. “Новые 135 уроков здоровья, или школа докторов природы”,2007
14. Периодик басмалар: «Дополнительное образование», «Начальная школа», «Педсовет»,«Мәгариф» һ.б..
15. Сагдиева И.Т. «Башлангыч мәктәптә ата-аналар җыелышы”,Казан,2011ел
16. Сазонов Е.Ю. Театр наших детей. Издание «знание», М., 2008 г.
17. Саттарова Н.Х. “1-3классларда класстан тыш укуны оештыру тәҗрибәсеннән”,2006ел
18. Сорокина Г.И «Детская риторика в рассказах, стихах, рисунках». Учебник,  М., 2006 г.
19. Хәсәнова М.Х. “Сөйләм үстерүдә юмор файдалы”,Казан,2005ел
20. Хәсәнова М.Х., Г.М.Сафиуллина “Риторика дәресләре”,Казан,2005ел
21. Что и как в театре кукол. Сборник статей. Изд. «Искусство», М., 2008 г
22. Чурова В. Г. «Методика и организация театральной деятельности младших школьников» ,2007г.